**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА БОГДАШКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**БОГДАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Рус Богдашкиносы ав. **КАРАР**

«04» октябрь 2024 ел № 4

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлеге Рус Богдашкиносы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Богдашкино авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, “Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Богдашкино авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлегенең Рус Богдашкиносы авылында Чапаев, Гагарин, Бауман урамнарында, Совет урамындагы 40-54,43-65 йортларда, Мәктәп урамындагы 16-34 йортларда, Мәктәп тыкрыгында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының беренче этабын уздыруны 2024 елның 16 октябрендә Совет урамы, 43нче йорт янында 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлегенең Рус Богдашкиносы авылында Мәктәп урамындагы 2-14 йортта, Совет урамындагы 2-36, 1-35 йортларда яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының икенче этабын уздыруны 2024 елның 16 октябрендә Совет урамы, 17нче йорт янында 11 сәгать 00 минутка билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлегенең Рус Богдашкиносы авылында Фрунзе урамында 2-16, 1-11нче йортларда, Октябрь урамында 2-20, 1-33нче йортларда яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының өченче этабын уздыруны 2024 елның 16 октябрендә Октябрь урамы, 20нче йорт янында 12 сәгать 00 минутка билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлегенең Рус Богдашкиносы авылында Пушкин, Тукай, Фрунзе урамында 13-39нчы йортларда, Октябрь урамында 22-74, 35-65нче йортларда яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының

дүртенче этабын уздыруны 2024 елның 16 октябрендә Октябрь урамы, 48нче йорт янында 13 сәгать 00 минутка билгеләргә.

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен Рус Богдашкиносы авылында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлү тәртибен территориаль билгеләнеш буенча башкарырга.

6. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитет тарафыннан башкарыла.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Богдашкино авыл җирлегенең Рус Богдашкиносы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидларыннан тыш, балачактан инвалид булганнардан тыш, 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгәгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- урам утларын көйләү.»

«РИЗА» «КАРШЫ».

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (игълан итәргә) http://pravo.tatarstan.ru һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлеге мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.
8. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Богдашкино авыл җирлеге башлыгы А.Л. Михайлова